СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**12.07.2017**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 207**

«Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлыгы барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 11 апрелендәге 78 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 29 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 22 декабрендәге 431-ФЗ номерлы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, «Россия Федерациясе Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 23 июнендәге 453 номерлы Указын, «Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы Указын исәпкә алып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлыгы барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 11 апрелендәге 78 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карарына (алга таба - Нигезләмәне) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– 4, 5 пунктларны яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибе һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә (алга таба -

Комиссия), әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендә форма буенча төзелгән хәбәрнамә җибәрә .

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында Комиссия билгеләнгән тәртиптә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлардан, аларда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар алырга һәм билгеләнгән тәртиптә федераль дәүләт хакимияте органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрергә хокуклы.

5. Хәбәрнамәләрне карау, карарлар кабул итү, Зеленодольск муниципаль районы Советының 2017 елның 12 июлендәге 206 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия тарафыннан башкарыла.»;

– Нигезләмәнең 6-9 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

– «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлыгы барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау хакында» Зеленодольск муниципаль районы Советының 2016 елның 11 апрелендәге 78 номерлы карарына кушымта яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru)хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы
Советының
2017 елның 12 июлендәге
207 номерлы карарына
кушымта

«Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлыгы барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмә кушымта

______________________________
(танышу турында билге)

______________________________
Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясенә

.

______________________________
(Ф.И.Ат.и., вазыйфа)

## Вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлыгы барлыкка килү турында ХӘБӘРНАМӘ

Вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлыгы барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәклесен ассызыкларга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүгә нигез булып торган хәлләр:

______________________________

Гамәлгә ашырылуына шәхси кызыксынучанлык йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган вәкаләтләр:

______________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителгән чаралар:

______________________________

Әлеге хәбәрнамәне караганда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия утырышында шәхсән катнашырга (ниятләмим) ниятлим(кирәклесен ассызыкларга).

«__» 20__ ел ______________________ ______________________

(хәбәрнамә җибәргән затның имзасы) (имзаның аңлатмасы)